**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.51, с.Н.Каменка, 423114

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзәк урам, 51 йорт, Түбән Кәминкә авылы, 423114

тел./факс (84396) 2-35-21 email: N kam @tatar.ru

**№ 05** **24 апрель 2025 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне оештыру һәм аның шартлары турында» 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы хатын үтәү йөзеннән, авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәтенә түләүне оештыру һәм аның шартлары турында» 2019

елның 23 апрелендәге 7 номерлы карарына (31.01.2023 ел № 3; 20.06.2024 ел № 7; 12.12.2024 ел № 12 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмә» нең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның вазыйфаи окладлы 28200,00 сум (Егерме сигез мең ике йөз сум) күләмендә билгеләнә».

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме сакланып калганда һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарганда, хезмәткәрләрнең хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2025 елның 30 апреленә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районының
Түбән Кәминкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Яхина С.А